СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.06.2024 Баулы шәһәре № 256

Баулы муниципаль район Советының
2022 елның 27 октябрендәге 141 номерлы
«Баулы муниципаль районы территориясендә
автомобиль транспорты, шәһәр җир өсте
электр транспорты һәм юл хуҗалыгында
муниципаль контроль турында Нигезләмәне
раслау турында» карарына үзгәрешләр
кертү хакында

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында «Татарстан Республикасы Законының 12 һәм 13.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасының 2024 елның 12 апрелендәге 17-ЗРТ номерлы Законына ярашлы, Баулы муниципаль район Советы **КАРАР ИТӘ**:

1. Баулы муниципаль район Советының 2022 елның 27 октябрендәге 141 номерлы «Баулы муниципаль районы территориясендә автомобиль транспорты, шәһәр җир өсте электр транспорты һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау турында» карарына (2023 елның 26 октябрендәге 226 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Баулы муниципаль район территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында Нигезләмәдә:

1.2. пунктын в) пунктчасы белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«в) транспорт чараларының җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы түләүле автомобиль юллары, җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы

автомобиль юлларының түләүле участоклары буенча транспорт чарасының йөрү өчен түләү кертү тәртибен үтәү өлешендә йөрүен гамәлгә ашыруга.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат Рәсми порталында pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Баулы муниципаль районы рәсми сайтында bavly.tatar.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 сентябрендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль район Советының икътисади үсеш, эшмәкәрлек, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы Рәисе И.И. Гозәеров